Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXVI-9**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 19 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 15 июлендәге “Балык Бистәсе муниципаль районының “Йолдыз” фонды Уставын һәм Советын раслау турында” гы XI-6 номерлы карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районы “Йолдыз” фонды Советы составына үзгәрешләр кертү турында

Аерым затларның башка эшкә күчүе сәбәпле, Россия Федерациясе Граждан кодексының 123.19 маддәсе, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 69 маддәсе, “Коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар турында”1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 15 июлендәге “Балык Бистәсе муниципаль районының “Йолдыз” фонды Уставын һәм Советын раслау турында” XI-6 номерлы карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районы “Йолдыз” фонды Уставының 4.2 пунктын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 15 июлендәге “Балык Бистәсе муниципаль районының “Йолдыз” фонды Уставын һәм Советын раслау турында” гы XI-6 номерлы карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районы “Йолдыз” фонды Советы составына (алга таба – фонд Советы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) Фонд Советы составыннан Р.Х. Хәбибуллинны, Р.Д. Исмәгыйлевны чыгарырга;

1.2) Фонд Советы составына кертергә:

Ногманова Илсия Мәлик кызын – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисен;

Җамалиев Рөстәм Рәсим улын – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгын (кушымта).

2. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2018 елның 19 ноябрендәге
XXXVI-9 номерлы карарына
кушымта

**Балык Бистәсе муниципаль районының**
**“Йолдыз” фонды Советы**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| И.Г. Ибраһимов | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы урынбасары, фонд Советы рәисе |
| | Фонд Советы әгъзалары: |
| И.М. Ногманова | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Р.Р. Җамалиев | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы |